**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районы**
**«Ивашкино авыл җирлеге»**
**муниципаль берәмлеге**
**ГРАЖДАННАРЫ ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

2023 елда Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Ивашкино авыл җирлеге составына керүче Ивашкино, Әккәрәй торак пунктларында үзара салым кертү турында

21 октябрь 2022 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Ивашкино авыл җирлеге составына керүче Ивашкино, Әккәрәй торак пунктларда гражданнар җыены **КАРАР ИТТЕ:**

1. 2023 елда Чирмешән муниципаль районы Ивашкино авыл җирлеге составына керүче Ивашкино, Әккәрәй торак пункты территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 600 сум күләмендә үзара салым кертергә көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүчеләрдән, Донецк халык республикасында һәм Луганск халык республикасында махсус хәрби операциядә булган гражданнардан, 1 төркем инвалидлардан, ялгыз картлардан һәм 90 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан тыш.

1. Алынган чараларны җибәрергә:

- Ивашкино, Әккәрәй торак пунктларында җәйге һәм кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны төзекләндерү, карап тоту (юл кырыйларын чабу, урам-юл челтәрен норматив хәлгә китерү, триммер өчен бензин, запас частьләр сатып алу һәм хезмәтләр өчен түләү, юлларны грейдерлау, урамнарны кышкы чорда кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, хезмәтләр өчен түләү, чокырларга ремонт ясау өчен вак таш сатып алу, хезмәтләр өчен түләү), югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу чыгымнары;
- Ивашкино, Әккәрәй торак пунктларында урам утларын монтажлау, кую, ремонтлау, карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү, урам утларына кулланган электр энергиясе өчен чыгымнарны түләү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу;
- Ивашкино торак пунктының Заречная урамындагы күперне капиталь ремонтлау, проект-смета документлары әзерләү, югарыда күрсәтелгән эшләрне башкару өчен кирәкле материаллар алу, хезмәт күрсәтүләр өчен түләү;
- Ивашкино торак пунктындагы чишмә территориясен төзекләндерү (коймаларны буяу, чишмә территориясендәге иске агачларны кисү, чыгару), югарыда күрсәтелгән эшләрне башкару өчен кирәкле материаллар алу, хезмәтләр өчен түләү.

2. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Ивашкино авыл җирлегенең рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Ивашкино авыл җирлеге башлыгы: Н.А. Емельянов